Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы

# КАРАР

9 июнь 2021 ел №11

**Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 19.04.2016 8 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына һәм «Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына гражданнарның, муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 24 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы», Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставы нигезендә, Кукмара районы прокурорының 2021 елның 02 апрелендәге 02-08-01/21 номерлы протестын карап, Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 19.04.2016 8 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы

йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

б) түбәндәге эчтәлекле 11 нче пунктны өстәргә:

«6.1. Зур Сәрдек авыл Советы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат депутат булып сайланган, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырган яисә даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны туктаткан көннән соң дүрт ай эчендә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук, хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр башкарылган очракта, белешмәләр тапшыру елыннан алдагы һәр ел (хисап чоры) өчен белешмәләр тапшыра. Хисап чорында мондый алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта Татарстан Республикасы Президентына, керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен, махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсы (dohod.tatar.ru) ярдәмендә әлеге Нигезләмәгә кушымта формасы буенча хәбәрнамә юллау юлы белән хәбәр итә.

Әлеге пункт белән каралган хәбәрнамә, шулай ук белешмәләр (хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр башкарылган очракта,) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокта бирелә. Авыл җирлеге вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими булмаган нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы зат тарафыннан имзаланган кәгазь чыганактагы хәбәрнамәнең күчермәсе Кукмара муниципаль районында коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш»;

2) 7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат (авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары депутатлары муниципаль вазыйфаларын биләүче һәм даими булмаган нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы затлардан тыш) ел саен Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокта түбәндәгеләрне тапшыра:»

3) 7 пунктның 3 пунктчасында «оешмалар)» сүзеннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә;

4) түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 19.04.2016 8 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәгә Кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты**

___________________________________

**хәбәрнамә.**

Мин, ______________________________________________________________________ ,

*фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының исеме*

«___»_____________ _______ елгы, паспорт сериясе ____№________

______________________________________________________________________________ ,

*паспортны бирү датасы һәм биргән орган*

_____________________________ муниципаль районы

*муниципаль район исеме*

____________________________________ авыл җирлеге депутаты

*авыл җирлегенең вәкиллекле органы исеме*

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $12^1$ статьясындагы 4.2 өлеше һәм «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19

июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 4.1 өлеше нигезендә Сезгә «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган (безнең (минем һәм минем ирем (хатыным) керемебезнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми керемнән артып китә торган җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча килешүләр) минем (хатыным) һәм (яисә) балигъ булмаган балалар тарафыннан хисап чоры дәвамында 20___ елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр алыш-биреш булмады, дип хәбәр итәм.

Әлеге мәгълүматларның дөреслеген раслыйм.

«___»___________ 20____ ел

_______________________________________________

*хәбәрнамә тапшырган затның имзасы*

_____________________________________________________________________________

*(хәбәрнамәне кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының исеме һәм имзасы*».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, махсус мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы Ф.М.Фаттахов

ОГРН 1021607753232
ИНН 1623001727